# Татар теле һәм әдәбияты атналыгы нәтиҗәләре

1 нче февральдән 6 нчы февральгә кадәр гимназиядә татар теле һәм әдәбияты атналыгы үтте.

Атна планы төрле яшьтәге төркем укучыларның реаль коммуникатив ихтыяҗларын исәпкә алып төзелде, һәм аның эчтәлеге коммуникатив-мәҗбүри юнәлеш, мәгълүматлылык, белем бирү кыйммәте һәм һәркем өчен мөмкин булган таләпләргә җавап бирде. Атнаның барлык чаралары да укучыларның иҗади активлыгын стимуллаштыруга юнәлдерелгән иде. Анда 1-11 сыйныф укучылары катнашты. Татар теле һәм әдәбияты укытучылары утырышында бу атнаның эше планлаштырылган иде.

1нче И сыйныфы укучылары район үзәк китапханәсенә экскурсиягә барды. Алар белән “Дуслык елмаюдан башлана” дигән чара үткәрелде. Чарада балалар төрле халык әкиятләрен белүләрен, төрле телләрдә шигырьләр сөйли алуларын күрсәтте. Шулай ук китапханәгә язылып, китаплар алдылар.

Балтач гимназиясенең 1нче инженер сыйныфында укучылар Карадуган авылындагы М. Җәлил музеенда экскурсиядә булды. Биредә укучыларга герой-шагыйрьнең тормыш юлы, батырлыгы, шигырьләре турында сөйләделәр, кызыклы экспонатлар белән таныштырдылар. Балалар М.Җәлилнең шигырьләрен яттан сөйләделәр. Шулай ук Себер тракты музее экспонатларын да карадылар. Ахырдан Зарипова Гүзәлия әзерләгән табында тәмле коймаклар, кайнатмалар белән сыйландылар.

8 класс укучылары өчен “Туган телем- горурлыгым” дигән әдәби чара үткәрелде. Әлеге чараның беренче өлешендә милләтебезнең мәдәнияте, мили уеннары, мәшһүр кешеләре турында кыскача күзәту бирелде. Икенче өлешендә укучылар арасында телебез белән тирәнтен кызыксынучы, тарихыбызны һәм мәдәниятебезне яхшырак белүчене билгеләү өчен викторина сораулары тәкъдим ителде.

Балтач гимназиясендә 2021 – Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы кысаларында «Киләчәк бүген дә аналар кулында» дигән җылы очрашу-чара узды. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Рәйсә Әхмәтова җыенны мәгънәле, итагатьле, гади итеп алып барды. Таш булып каткан күңелләр дә эрерлек иде хәтта. Биредә сыйныф җитәкчеләре, эти-әниләр, килгән кунаклар һәм район мәгариф идарәсе җитәкчесе Алия Шагаева катнашында бала тәрбияләү мәсьәләсендә фикер алыштылар.

5-8 нче класслар өчен "Китап-белем чишмәсе"дигән әдәби викториналар үтте. Укучылар китапның белем алуда зур терәк булуына тагын бер кат инандылар. "Матур сөйләү серләре" чарасында уеннар аша йөгерек, укучылар оста сөйләшү күнекмәләре алдылар.

Китапханәдә 7нче, 11нче класслар өчен шагыйрь Һади Такташның 120 еллыгына әдәби –музыкаль кичә үткәрелде, Такташның тормыш юлы, иҗаты буенча мәгълүматлар бирелде, укучылар Такташның әсәрләрен сәнгатьле сөйләделәр, туган телгә, туган җиргә багышланган җырлар башкардылар. Китапханәче Ибраһимова Асия апа шагыйрь китапларыннан күргәзмә оештырды.

"Татарстан-дуслык иле, һәрбер милләт- аның гөле" дигән видеошигырь чарасы үтте, 2-11нче класстан төрле милләт балалары туган телләрендә шигырьләр сөйләделәр. Танылган татарларыбызга багышланган стенд ясалды.

"Герой шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 115 ел", Шул уңайдан гимназиядә "Үлемсезлеккә юл" дигән әдәби чара үткәрелде. 6нчы сыйныф укучылары, Җәлилнең тормышы һәм иҗаты турында фильм карап, белемнәрен тагы да ныгыттылар, шигырьләрен, җырларын тыңладылар, үзләрен кызыксындырган сорауларга җавап алдылар. Китапханәче Асия Гыйльфановна шагыйрь иҗатына багышланган күргәзмә белән таныштырды, балалар өчен язылган шигырьләрен укыды. Туган тел һәм әдәбият дәресләрендә батыр шагыйрь, аның иҗаты турында әңгәмәләр оештырылды.

Атна дәвамында һәр сыйныфта туган телгә, аның талантлы шәхесләренә багышланган класс сәгатьләре, китап уку кирәклеге турында тематик әңгәмәләр үткәрелде.

Татар теле һәм әдәбияты атналыгы планы үтәлде, барлык чаралар да яхшы методик дәрәҗәдә үтте һәм укучыларга интеллектуаль һәм таныпп-белү сәләтен күрсәтергә, эрудицияне һәм гомуми белем бирү тирәлеген киңәйтергә ярдәм итте. Моңа иҗади эшләүче татар теле һәм әдәбияты укытучылары да ярдәм итте: Әхмәтова Р.Ш., Идрисова Н.М., Габделганиева Ч.М., Гайнуллина Р.Ф., Гыйниятуллина Д.Х.Үткәрелгән чаралар нәтиҗәләре буенча укучыларның эшләре атналык барышында фән буенча класстан тыш эшнең тормышка ашырылуын дәлилли: укучыларда кызыксынучанлыкны, иҗади сәләтләрне үстерә, татар теле һәм әдәбиятына карата кызыксыну уята.